**СОГЛАШЕНИЕ**
**между Правительством Республики Татарстан и Правительством Республики Башкортостан о торгово-экономическом, научно-техническом, социальном и культурном сотрудничестве**

Правительство Республики Татарстан в лице Президента Республики Татарстан Минниханова Рустама Нургалиевича, действующего на основании Конституции Республики Татарстан, с одной стороны, и Правительство Республики Башкортостан в лице временно исполняющего обязанности Главы Республики Башкортостан Хабирова Радия Фаритовича, действующего на основании Конституции Республики Башкортостан, с другой стороны, именуемые в дальнейшем Стороны,

руководствуясь Конституцией Российской Федерации, федеральным законодательством, законодательством Республики Татарстан и законодательством Республики Башкортостан (далее – законодательство),

в целях развития межрегиональных связей на основе принципов равноправия и взаимной выгоды, укрепления правовой основы сотрудничества с учетом политических и экономических изменений в Российской Федерации,

признавая, что расширение взаимовыгодного сотрудничества отвечает интересам населения Республики Татарстан и Республики Башкортостан и способствует экономическому развитию Республики Татарстан и Республики Башкортостан,

выражая взаимную заинтересованность в развитии двусторонних связей на стабильной и долгосрочной основе и желая создать для этого соответствующие организационные, экономические, правовые и иные необходимые условия, согласились о нижеследующем:

Статья 1

Стороны развивают сотрудничество на основе взаимного уважения, равенства, партнерства и экономической выгоды.

Стороны в пределах своей компетенции создают благоприятные условия для разностороннего развития отношений.

В соответствии с законодательством и в пределах предоставленных полномочий Стороны содействуют сотрудничеству юридических лиц, предпринимателей, зарегистрированных и осуществляющих хозяйственную деятельность на территориях Республики Татарстан и Республики Башкортостан (далее – хозяйствующие субъекты Сторон).

Статья 2

Стороны воздерживаются от действий, которые могли бы нанести экономический или иной ущерб друг другу, согласовывают и обмениваются

информацией о намечаемых решениях, принятие которых может затронуть права и законные интересы Сторон.

Статья 3

В области торгово-экономического, инвестиционного и инновационного сотрудничества Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

создают благоприятные условия для деятельности хозяйствующих субъектов Сторон, а также для инвестирования в сферы экономики, представляющие взаимный интерес;

способствуют развитию торгово-экономических связей между хозяйствующими субъектами Сторон;

способствуют расширению кооперационных связей между хозяйствующими субъектами Сторон;

способствуют осуществлению взаимопоставок важнейших видов продукции производственно-технического назначения и потребительских товаров в соответствии с требованиями законодательства;

разрабатывают совместные проекты, направленные на развитие экономического и инновационного потенциала Республики Татарстан и Республики Башкортостан, проводят обмен проектами и специалистами по отраслям, представляющим взаимный интерес;

содействуют созданию условий для установления и расширения деловых контактов между хозяйствующими субъектами Сторон, разработке и реализации программ по развитию и поддержке предпринимательства в Республике Татарстан и Республике Башкортостан;

способствуют формированию эффективной системы коммуникации в области науки, технологий и инноваций, а также выстраиванию взаимодействия сектора исследований и разработок с реальным сектором экономики;

взаимодействуют в сфере инвестиционной и инновационной деятельности, в том числе разрабатывают и реализуют меры по стимулированию инвестиционной активности с целью повышения конкурентоспособности и роста экономики Республики Татарстан и Республики Башкортостан;

организуют бизнес-миссии и презентации инвестиционных площадок и инвестиционного потенциала;

обмениваются опытом по реализации инвестиционных проектов в рамках официальных визитов и рабочих встреч;

информируют о проведении на территориях Республики Татарстан и Республики Башкортостан инвестиционных форумов, конференций и иных мероприятий инвестиционной направленности;

осуществляют взаимодействие и обмен информацией по вопросам создания и функционирования особых экономических зон;

развивают механизмы государственно-частного партнерства;

обмениваются информацией о нормативных правовых актах Республики Татарстан и Республики Башкортостан и их проектах в сфере развития инвестиционной деятельности;

способствуют развитию транспортного сообщения между Республикой Татарстан и Республикой Башкортостан.

Статья 4

В области сельского хозяйства, государственного ветеринарного надзора и здоровья животных Стороны в пределах своей компетенции и в соответствии с законодательством взаимодействуют по следующим направлениям:

растениеводство, селекция, семеноводство, взаимное использование передовых технологий, растительного генофонда, экологически чистых методов и средств защиты растений при возделывании зерновых и прочих сельскохозяйственных культур;

животноводство, разведение, содержание и кормление высокопродуктивных сельскохозяйственных животных на базе современных технологий; оказание содействия осуществлению технического обновления механизированных ферм;

биотехнология, биотехнологическое управление производством сельскохозяйственных культур и размножением животных;

перерабатывающая, пищевая промышленность, комплексное использование средств механизации и автоматизации производственного процесса.

Статья 5

Стороны в пределах своей компетенции и в соответствии с законодательством способствуют обмену научно-практической информацией о достижениях в области здравоохранения, обмену делегациями в целях изучения передового опыта в области охраны здоровья населения и повышения качества предоставляемой медицинской помощи на территориях Республики Татарстан и Республики Башкортостан.

Статья 6

В области социальной защиты и занятости населения Республики Татарстан и Республики Башкортостан в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

развивают сотрудничество по вопросам принятия и реализации нормативных правовых актов в данных областях, осуществляют взаимодействие и обмен опытом работы по реализации программ социально-экономического развития, снижения доли населения с доходами ниже прожиточного минимума и увеличения доходов граждан, социальных программ

поддержки семьи, материнства, детства, граждан пожилого возраста и инвалидов;

обмениваются делегациями органов социальной защиты и службы занятости населения и учреждений социального обслуживания населения для изучения опыта работы в части внедрения новых социальных технологий;

обмениваются информационно-аналитическими материалами по уровню жизни населения, в том числе уровню бедности, состоянию безработицы и положению на рынке труда;

обмениваются информацией и опытом работы по реализации профориентационных мероприятий, в том числе для инвалидов, учащихся образовательных организаций и других категорий населения;

## Статья 7

В области охраны окружающей среды и обеспечения экологической безопасности Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

обмениваются информацией о международном сотрудничестве, проводимых в Республике Татарстан и Республике Башкортостан мероприятиях по вопросам охраны окружающей среды и обеспечения экологической безопасности;

обеспечивают сотрудничество в области ведения красных книг, охраны и использования объектов животного мира, водных биоресурсов;

способствуют сотрудничеству и обмену опытом по вопросам: обращения с отходами производства и потребления; внедрения новых технологий сортировки, переработки и утилизации отходов, в том числе твердых коммунальных отходов; регулирования недропользования; воспитания экологической культуры населения;

развивают сотрудничество в области совершенствования системы управления природоохранной деятельности.

## Статья 8

В области культуры Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

осуществляют обмен информацией о предстоящих культурных событиях и мероприятиях Республики Татарстан и Республики Башкортостан, в том числе имеющих международный характер, с целью возможного участия в них коллективов и исполнителей из Республики Татарстан и Республики Башкортостан;

оказывают содействие укреплению и развитию культурных связей;

осуществляют взаимодействие по организации гастролей творческих коллективов, обменных музейных, художественных и книжных выставок;

осуществляют взаимодействие и обмен опытом по вопросам сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия.

Статья 9

В области архивного дела Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

осуществляют обмен опытом и информацией о нормативных и методических разработках, информационных технологиях, применяемых в деятельности архивных органов и учреждений;

принимают участие в организации и проведении научно-практических конференций, семинаров, совещаний, выставок архивных документов, в подготовке публикаций по документам Архивного фонда Российской Федерации;

оказывают содействие друг другу в доступе к архивным документам и научно-справочным материалам, необходимым для исследований и удовлетворения социально-правовых запросов граждан в соответствии с законодательством.

Статья 10

В области образования и науки Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

проводят совместные конференции;

реализуют совместные научно-исследовательские проекты;

обмениваются опытом по разработке современных образовательных технологий, проектов нормативных правовых актов, регулирующих деятельность образовательных организаций;

осуществляют взаимодействие и обмен опытом по вопросам сохранения и развития этнокультурного образования.

Статья 11

В области информатизации и связи Стороны в пределах своей компетенции и в соответствии с законодательством:

развивают взаимовыгодное сотрудничество в области информационных технологий за счет реализации различных инвестиционных проектов;

обмениваются информацией и опытом работы органов государственной власти Республики Татарстан и Республики Башкортостан;

стимулируют развитие наукоемких отраслей через создание совместных предприятий или технологического сотрудничества и обучения.

Статья 12

В области спорта Стороны в пределах своей компетенции и в соответствии с законодательством осуществляют содействие участию спортсменов и спортивных сборных команд Республики Татарстан и Республики Башкортостан в спортивных мероприятиях.

Статья 13

В области государственной молодежной политики Стороны в соответствии с законодательством и в пределах своей компетенции:

оказывают содействие участию молодежи в мероприятиях, реализуемых Сторонами (форумы, слеты, семинары, фестивали, конкурсы);

осуществляют взаимодействие и обмен опытом в сфере развития креативных индустрий (при наличии);

обмениваются информационно-аналитическими материалами, методическими рекомендациями по реализации наиболее успешных практик по работе с разными категориями молодежи.

Статья 14

В области туризма Стороны в соответствии с законодательством в пределах своей компетенции:

осуществляют обмен информацией о предстоящих мероприятиях Республики Татарстан и Республики Башкортостан в сфере туризма;

оказывают содействие в установлении взаимных контактов между туристскими организациями Республики Татарстан и Республики Башкортостан.

Статья 15

В области строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Стороны в пределах своей компетенции:

обмениваются опытом организации строительства, жилищно-коммунального хозяйства и в градостроительной политике;

обмениваются делегациями органов государственной власти в области строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства;

участвуют в международных, республиканских и областных выставках, семинарах и конференциях строительной, градостроительной и архитектурной тематики.

Статья 16

В области средств массовой информации Стороны в пределах своей компетенции и в соответствии с законодательством осуществляют содействие в

размещении в средствах массовой информации Республики Татарстан и Республики Башкортостан материалов, посвященных общественно-политической, торгово-экономической, научной, социальной и культурной жизни Республики Татарстан и Республики Башкортостан, а также организации обмена между средствами массовой информации Республики Татарстан и Республики Башкортостан.

Статья 17

Настоящее Соглашение не налагает на подписавшие его Стороны финансовых или имущественных обязательств.

Статья 18

В целях реализации Соглашения Стороны вправе заключать договоры (соглашения), планы мероприятий, осуществлять совместные мероприятия в конкретных областях сотрудничества.

Настоящее Соглашение не затрагивает обязательств Сторон по заключенным договорам (соглашениям) с третьими сторонами и не может быть использовано в ущерб интересам какой-либо из них или служить препятствием для выполнения взятых перед третьими сторонами обязательств.

Статья 19

Стороны оперативно рассматривают возникающие в процессе реализации настоящего Соглашения вопросы и принимают необходимые меры по их положительному разрешению в соответствии с законодательством.

Статья 20

Разногласия, связанные с толкованием и (или) применением положений настоящего Соглашения, разрешаются путем проведения переговоров и консультаций между Сторонами.

Статья 21

Настоящее Соглашение вступает в силу со дня его подписания и действует в течение пяти лет. В дальнейшем Соглашение автоматически продлевается на следующие пять лет, если ни одна из Сторон не заявит в письменной форме о своем желании прекратить его действие.

Настоящее Соглашение прекращает действие по истечении шести месяцев со дня получения одной из Сторон письменного уведомления от другой Стороны о своем намерении прекратить его действие.

Изменения в настоящее Соглашение вносятся по взаимному согласию Сторон дополнительными соглашениями, являющимися неотъемлемой частью настоящего Соглашения.

Совершено в г. Уфе «18» апреля 2019 года в двух экземплярах, на русском, татарском и башкирском языках, имеющих одинаковую силу, по одному экземпляру для каждой из Сторон.

| | |
|---|---|
| За Правительство Республики Татарстан | За Правительство Республики Башкортостан |
| Президент Республики Татарстан | Временно исполняющий обязанности Главы Республики Башкортостан |
| Р.Н. Минниханов | Р.Ф. Хабиров |

19.04.2019
№ 17

**Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Башкортостан Республикасы Хөкүмәте арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турында**

**КИЛЕШҮ**

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов йөзендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте, бер яктан, һәм Башкортостан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Башкортостан Республикасы башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Хәбиров Радий Фәрит улы йөзендә Башкортостан Республикасы Хөкүмәте, икенче яктан, алга таба Яклар дип аталып,

Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Башкортостан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына (алга таба – законнар) таянып,

тигез хокуклылык һәм үзара файда принциплары нигезендә төбәкара бәйланышларны үстерү, Россия Федерациясендәге сәяси һәм икътисадый үзгәрешләрне исәпкә алып, хокукый нигезне ныгыту максатларында,

үзара файдалы хезмәттәшлекне киңәйтү Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы халкы мәнфәгатьләренә туры килүен һәм Башкортостан Республикасы һәм Татарстан Республикасы икътисадый үсешенә булышлык итүен танып,

ике яклы элемтәләрне тотрыклы һәм озак вакытлы нигездә үстерүгә үзара кызыксыну күрсәтеп һәм моның өчен тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка кирәкле шартлар булдырырга теләп, түбәндәгеләр турында килештеләр:

1 статья

Яклар хезмәттәшлекне үзара хөрмәт рухында, тигезлек, партнерлык һәм икътисадый файда нигезендә үстерә.

Яклар үз компетенцияләре чикләрендә мөнәсәбәтләрне төрле яклап үстерү өчен уңай шартлар булдыра.

Законнар нигезендә һәм бирелгән компетенцияләре чикләрендә Яклар Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы территорияләрендә теркәлгән һәм хуҗалык эшчәнлеген алып баручы юридик затларның, эшкуарларның (алга таба – Якларның хуҗалык итүче субъектлары) хезмәттәшлегенә булышлык итә.

2 статья

Яклар бер-берсенә икътисадый яисә башка зыян китерердәй гамәлләрдән тыела, аларны кабул итү Якларның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә

кагылырга мөмкин булган карарларны килештерә һәм алар турында мәгълүмат алмаша.

3 статья

Яклар сәүдә-икътисадый, инвестицияләр һәм инновацияләр буенча хезмәттәшлек өлкәсендә законнарга нигезләнеп үз компетенцияләре чикләрендә:

Якларның хуҗалык итүче субъектлары эшчәнлеге өчен, шулай ук икътисадның үзара кызыксыну тудыручы өлкәләренә инвестицияләр кертү өчен уңайлы шартлар булдыра;

Якларның хуҗалык итүче субъектлары арасында сәүдә-икътисадый багланышларны үстерүгә ярдәм итә;

Якларның хуҗалык итүче субъектлары арасында кооперация элемтәләренең киңәюенә ярдәм күрсәтә;

җитештерү-техник билгеләнештәге продукциянең кирәкле төрләрен, халык куллану товарларын һәм азык-төлек кайтаруны башкаруга законнар нигезендә булышлык итә;

Татарстан Республикасының һәм Башкортостан Республикасының икътисадый һәм инновация мөмкинлекләрен үстерүгә юнәлтелгән уртак проектлар эшли, уртак кызыксыну уята торган тармакларга кагылышлы проектлар һәм белгечләр алмаша;

Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы территорияләрендә эшчәнлек алып баручы эшкуарлык субъектлары арасында эшлекле багланышлар булдыру һәм аларны киңәйтү, Татарстан Республикасында һәм Башкортостан Республикасында эшкуарлыкны үстерү һәм аңа булышлык күрсәтү программалары эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру өчен шартлар булдыруга ярдәм итә;

фән, технологияләр һәм инновацияләр өлкәсендә нәтиҗәле коммуникацияләр системасын булдыруга, шулай ук тикшеренүләр һәм эшләнмәләр секторының икътисадның реаль секторы белән хезмәттәшлеген урнаштыруга ярдәм итә;

инвестиция һәм инновация эшчәнлеге өлкәсендә хезмәттәшлек итә, шул исәптән Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы икътисадының конкурентлыкка сәләтлелеген һәм үсешен көчәйтү максатында инвестиция активлыгына этәргеч бирү чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра;

бизнес-миссияләр һәм инвестиция мәйданчыкларын һәм инвестиция мөмкинлекләрен тәкъдим итүне оештыра;

рәсми сәфәрләр һәм эшлекле очрашулар кысаларында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру тәҗрибәсе уртаклаша;

Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы территорияләрендә инвестиция форумнары, конференцияләр һәм инвестицияләргә кагылышлы башка чаралар уздыру турында мәгълүмат бирә;

махсус икътисадый зоналар төзү һәм аларның эшчәнлеге мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә һәм мәгълүмат алмаша;

дәүләт-хосусый партнерлык механизмнарын үстерә;

Татарстан Республикасының һәм Башкортостан Республикасының инвестиция эшчәнлеген үстерү өлкәсенә кагылышлы норматив хокукый актлары һәм аларның проектлары турында мәгълүмат алмаша;

Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы арасында транспорт элемтәсен үстерүгә булышлык итә.

4 статья

Авыл хуҗалыгы, дәүләт ветеринария күзәтчелеге һәм терлекләрнең сәламәтлеге өлкәсендә Яклар үз компетенцияләре чикләрендә һәм законнар нигезендә түбәндәге юнәлешләр буенча хезмәттәшлек итә:

үсемлекчелек, селекция, орлыкчылык, бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын эшкәрткәндә яңа технологияләрне, үсемлекләр генофондын, үсемлекләрне саклауда экологик чиста ысулларны һәм чараларны бергәләп куллану;

терлекчелек, заманча технологияләргә нигезләнеп продукция бирүчәнлеге югары дәрәҗәдә булган авыл хуҗалыгы терлекләрен үрчетү, асрау һәм ашату; механикалаштырылган фермалар техникасын яңартуны башкаруда булышлык күрсәтү;

биотехнология, авыл хуҗалыгы культураларын җитештерүгә һәм терлекләр үрчетүгә биотехнологик идарә;

эшкәртү, азык-төлек сәнәгате, җитештерү процессын механикалаштыру һәм автоматлаштыру чараларын комплекслы файдалану.

5 статья

Яклар үз компетенцияләре чикләрендә һәм законнар нигезендә сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлар турында фәнни-гамәли мәгълүмат алмашуга, Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы территорияләрендә халык сәламәтлеген саклау һәм күрсәтелә торган медицина ярдәме сыйфатын күтәрү өлкәсендәге алдынгы тәҗрибәне өйрәнү максатларында делегацияләр алмашуга ярдәм итә.

6 статья

Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы халкын социаль яклау һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз компетенцияләре чикләрендә:

әлеге өлкәләрдә норматив хокукый актлар кабул итү һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлекне үстерә, социаль-икътисадый үсеш, яшәү минимумыннан түбән керемле халык өлешен киметү һәм гражданнарның керемнәрен арттыру программаларын, гаиләләргә, аналарга, балаларга, өлкән

яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга ярдәм күрсәтү буенча социаль программаларны гамәлгә ашыруда хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша;

яңа социаль технологияләрне гамәлгә кертү өлешендә эш тәҗрибәсен өйрәнү өчен социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү органнары һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре делегацияләре алмаша;

халыкның тормыш дәрәҗәсе, шул исәптән хәерчелек дәрәҗәсе, эшсезлек дәрәҗәсе һәм хезмәт базарындагы вазгыять буенча мәгълүмат-аналитика материаллары алмаша;

һөнәри юнәлеш бирү чараларын, шул исәптән инвалидлар, мәгариф оешмалары укучылары һәм халыкның башка категорияләре өчен дә, гамәлгә ашыру буенча мәгълүмат һәм эш тәҗрибәсе алмаша.

7 статья

Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз компетенцияләре чикләрендә:

халыкара хезмәттәшлек, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасында һәм Башкортостан Республикасында уздырыла торган чаралар турында мәгълүмат алмаша;

кызыл китапларны алып бару, хайваннар дөньясы объектларын, су биоресурсларын саклау һәм файдалану өлкәсендә хезмәттәшлек итүне тәэмин итә;

җитештерү һәм куллану калдыклары белән эшләү, калдыкларны, шул исәптән каты коммуналь калдыкларны, сортларга аеру, эшкәртү һәм утильләштерүнең яңа технологияләрен кулланышка кертү, җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу, халыкка экологик тәрбия бирү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлеккә һәм тәҗрибә алмашуга ярдәм итә;

табигатьне саклау эшчәнлегенә идарә системасын камилләштерү өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерә.

8 статья

Мәдәният өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз компетенцияләре чикләрендә:

Татарстан Республикасының һәм Башкортостан Республикасының булачак мәдәни вакыйгалары һәм чаралары, шул исәптән халыкара чаралар турында, аларда Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы коллективларына һәм башкаручыларына катнашу мөмкинлеге бирү максатларыннан чыгып, мәгълүмат алмаша;

мәдәни элемтәләрне ныгытуга һәм үстерүгә ярдәм итә;

иҗат коллективлары гастрольләрен, музей, сәнгать һәм китап күргәзмәләрен алмашып оештыру буенча хезмәттәшлек итә;

мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану, популярлаштыру һәм аларны дәүләт саклавын оештыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша.

9 статья

Архив эше өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз компетенцияләре чикләрендә:

архив органнары һәм учреждениеләре эшчәнлегендә файдаланыла торган архив эше өлкәсендәге норматив һәм методик эшләнмәләр, мәгълүмати технологияләр турында тәҗрибә һәм мәгълүмат уртаклаша;

фәнни-гамәли конференцияләр, семинарлар, киңәшмәләр, архив документлары күргәзмәләре оештыруда һәм уздыруда, Россия Федерациясе Архив фонды документлары нигезендә басмалар әзерләүдә катнаша;

тикшеренүләр һәм гражданнарның социаль-хокукый ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле архив документлары һәм фәнни-белешмә материаллардан файдалануга законнар нигезендә бер-берсенә булышлык күрсәтә.

10 статья

Мәгариф һәм фән өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз компетенцияләре чикләрендә:

уртак конференцияләр уздыра;

уртак фәнни-тикшеренү проектларын гамәлгә ашыра;

хәзерге заман мәгариф технологияләрен, мәгариф оешмалары эшчәнлеген җайга сала торган норматив хокукый актлар проектларын эшләү тәҗрибәсен алмаша;

этномәдәни белем бирүне саклап калу һәм үстерү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша.

11 статья

Мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә үз компетенцияләре чикләрендә Яклар:

төрле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру хисабына мәгълүмат технологияләре өлкәсендә үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерә;

мәгълүмат һәм Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эш тәҗрибәсе белән үзара уртаклаша;

уртак предприятиеләр яки технологик хезмәттәшлек һәм уку-укыту аша фәнгә таянучы тармакларны үстерүгә ярдәм итә.

12 статья

Спорт өлкәсендә үз компетенцияләре чикләрендә һәм законнар нигезендә Яклар Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы спортчыларының һәм җыелма спорт командаларының спорт һәм массакүләм спорт чараларында катнашуына ярдәм итә.

13 статья

Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз компетенцияләре чикләрендә:

яшьләрнең Яклар тарафыннан уздырыла торган чараларда (форумнар, слетлар, семинарлар, фестивальләр, конкурслар) катнашуына ярдәм итә;

креатив индустрияләрне (булган очракта) үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша;

мәгълүмат-аналитика материаллары, яшьләрнең төрле категорияләре белән эшләү буенча аеруча уңышлы практикаларны гамәлгә ашыруга кагылышлы методик тәкъдимнәр алмаша.

14 статья

Туристлык өлкәсендә Яклар законнар нигезендә һәм үз компетенцияләре чикләрендә:

Татарстан Республикасының һәм Башкортостан Республикасының туристлык өлкәсендә уздырылачак чаралары турында мәгълүмат алмаша;

Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы территорияләрендә эшчәнлек алып баручы туристлык оешмалары арасында үзара элемтәләр урнашуга ярдәм итә.

15 статья

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Яклар үзләренең компетенцияләре чикләрендә:

төзелешне оештыру, торак-коммуналь хуҗалык һәм шәһәр төзелеше сәясәте өлкәсендә тәҗрибә уртаклаша;

төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт хакимияте органнары делегацияләре алмаша;

төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык тематикасына халыкара, республика һәм өлкә дәрәҗәсендәге күргәзмәләрдә, семинарларда һәм конференцияләрдә катнаша.

16 статья

Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә Яклар үз компетенцияләре чикләрендә һәм законнар нигезендә Татарстан Республикасының һәм

Башкортостан Республикасының иҗтимагый-сәяси, сәүдә-икътисадый, фәнни, социаль һәм мәдәни тормышына багышланган материалларны Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында бастыруда, шулай ук Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары арасында үзара алмашу оештыруга ярдәм итә.

17 статья

Әлеге Килешү аңа кул куйган Якларга финанс һәм мөлкәт йөкләмәләре салмый.

18 статья

Килешүне үтәү максатларында Яклар хезмәттәшлек итүнең конкрет өлкәләрендә шартнамәләр (килешүләр), чаралар планнары төзергә, уртак чаралар уздырырга хаклы.

Әлеге Килешү Якларның өченче як белән төзелгән шартнамәләрендә (килешүләрендә) билгеләнгән йөкләмәләренә кагылмый һәм аларның кайсысының булса да мәнфәгатьләренә зыян китереп файдаланыла яисә өченче як алдында үз йөкләмәләрен үтәвенә киртә була алмый.

19 статья

Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру барышында килеп чыккан четерекле мәсьәләләрне тиз арада карап тикшерә һәм законнар нигезендә аларны уңай хәл итү буенча кирәкле чаралар күрә.

20 статья

Яклар арасында әлеге Килешү нигезләмәләрен шәрехләү һәм (яисә) аларны куллануга кагылышлы килеп чыккан бәхәсле мәсьәләләр Яклар арасында сөйләшүләр һәм консультацияләр уздыру юлы белән хәл ителә.

21 статья

Әлеге Килешү аңа кул куелганнан соң үз көченә керә һәм биш ел дәвамында гамәлдә була. Алга таба Килешү, әгәр дә Якларның берсе үзенең әлеге Килешүне өзәргә теләве хакында язма рәвештә белдермәсә, аннан алдагы биш елга үзеннән-үзе озайтыла.

Әлеге Килешү Якларның берсе аның гамәлен туктату турында икенче Якның язма хәбәрен алганнан соң алты ай узгач үз көчен югалта.

Әлеге Килешүгә үзгәрешләр Якларның үзара ризалыгы белән әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган өстәмә килешүләр нигезендә кертелә.

2019 елның «18» апрелендә Уфа шәһәрендә һәркайсы рус, татар һәм башкорт телләрендә бер үк төрле көчкә ия ике нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә башкарылды.

Татарстан Республикасы
Хөкүмәте өчен

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Башкортостан Республикасы
Хөкүмәте өчен

Башкортостан Республикасы
башлыгы вазыйфаларын вакытлыча
башкаручы

Р.Ф. Хәбиров

19.04.2019
№ 17